СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 43 от 28.01.2021
на № __от _________

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының “Авыл җирендә, Байлар Сабасы шәһәр тибындагы поселогында эшләүче һәм яшәүче аерым категория гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында” 2006 елның 27 декабрендәге 105 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

“Мәгариф турында” Татарстан Республикасы Законының 14 һәм 25 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында” 2020 елның 18 июлендәге 38-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының “Авыл җирендә, Байлар Сабасы шәһәр тибындагы поселогында эшләүче һәм яшәүче аерым категория гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында” 2006 елның 27 декабрендәге 105 номерлы карарына (2017 елның 29 августындагы 162 номерлы, 2020 елның 6 октябрендәге 11 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

– 1 пунктны түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац белән тулыландырырга:
“Әлеге карарда күрсәтелгән социаль ярдәм чаралары алучыларга аларның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлары булмаган очракта бирелә.”.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р. Н. Минниханов